# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Кәкре Елга авыл җирлегенең Кәкре Елга торак пунктында 2026 елда гражданнарга үзара салым кертү турында

**2025 елның 30 октябрендәге** **2 нче номерлы**

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45, 69 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Кәкре Елга авыл җирлегенең Кәкре Елга торак пунктында гражданнар җыены нигезендә

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Кәкре Елга авыл җирлегенең Кәкре Елга торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, көндезге бүлектә укучы студентлардан, махсус хәрби операциядә катнашучылардан һәм аларның гаилә әгъзаларыннан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләрендә хәрби хезмәт узучы гражданнардан, 1 төркемнәр инвалидлардан тыш, 2026 елда 750 сум күләмендә үзара салым кертергә, аны 2 төркем инвалидлар өчен 375 сум күләмендә билгеләргә.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

-торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Яшьләр урамындагы юлны чокырларга ремонтлау һәм профильләштерү, су агызу торбасын урнаштыру һәм Кәкре Елга авылының 1 нче зиратына юлны ремонтлау);

- су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су җыю манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә торган башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау (материал, җайланмалар сатып алу, тишелешләрне бетерү, торбаларны алмаштыру);

- янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү (янгын сүндерү автомобилен йөртүченең хезмәтенә түләү, запас частьләр, ягулык-майлау материаллары сатып алу һәм янгын сүндерү автомобилен карап тоту);

- торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү (үлән чаптыру, триммер һәм трактор чапкычы өчен запас частьләр сатып алу, ягулык-майлау материаллары сатып алу, юлларны һәм территорияләрне кардан чистарту);

- Кәкре Елга авылының 1 нче зиратына инвентарьны саклау өчен хуҗалык бинасы китерү, Кәкре Елга авылының 1 нче зиратын тоташ эшләүче гербицид белән сатып алу һәм химик эшкәртү).

3.Әлеге карарны Кәкре Елга авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына урнаштырып халыкка җиткерергә, Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында (http://aznakaevo.tatarstan.ru), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (httr://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә бастырып чыгарырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче, Азнакай муниципаль районының Кәкре Елга авыл җирлеге башлыгы

И. М. Мөхәммәтҗанов